## III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XLIII СЕССИЯСЕ

## КАРАР №179

Мөслим «13» май 2020 ел

**Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 187 номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы Регламенты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. V бүлекне түбәндәге эчтәлекле 21.1 статья белән тулыландырырга:

«21.1. Статья

1. Район Советы карарлары, кичектергесез очракларда, район Советы депутатларын сораштыру юлы белән кабул ителә ала. Район Советының норматив хокукый характердагы карарлары, шулай ук район Советы утырышын чакыру, мәсьәләне район Советы утырышының көн тәртибенә кертү турында карарлар сораштыру юлы белән кабул ителә алмый.

2. Район Советы депутатларын сораштыру, район Советы Рәисенең язма йөкләмәсе буенча, район Советы Аппаратының Оештыру бүлеге тарафыннан район Советы депутатларының шәхси имзаларын җыю юлы белән башкарыла. Сораштыру кәгазенең бердәм формасы район Советы Рәисе тарафыннан раслана.

3. Сораштыру үткәрү һәм сораштыру юлы белән карауга кертелгән карар проекты турында район Советының һәр депутатына хәбәр ителергә тиеш. Анда Совет депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, сораштыру үткәрелгән дип санала.

4. Сораштыру юлы белән кабул ителгән һәм район Советы рәисе имзалаган карар һәм сораштыру кәгазе киләсе район Советы утырышы протоколына теркәлә. Район Советы утырышында рәислек итүче, шул ук утырышта район Советы депутатларына район Советының сораштыру юлы белән кабул ителгән карары һәм сораштыру нәтиҗәләре турында хәбәр итә. Мәгълүмат игътибарга алына, бу хакта беркетмә язмасы эшләнә.»

1.2. Регламентка түбәндәге эчтәлекле XII бүлек өстәргә:

«XII БҮЛЕК. ЮГАРЫ ӘЗЕРЛЕК РЕЖИМЫ, ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ РЕЖИМЫ, ЧИКЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ (КАРАНТИН), ГАДӘТТӘН ТЫШ ЯИСӘ ХӘРБИ ХӘЛ ЧОРЛАРЫНДА РАЙОН СОВЕТЫНЫҢ ЭШЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

47 Статья.

1. Татарстан Республикасы территориясендә яки Мөслим районы территориясендә югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш һәм хәрби хәл кертелгән чорда, Совет рәисе карары буенча, район Советы, шул исәптән аның аппараты эшчәнлегенең аерым тәртибе (алга таба – эшчәнлекнең аерым тәртибе) билгеләнергә мөмкин.

2. Эшчәнлекнең аерым тәртибе билгеләнгәндә Район Советы, район Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышлары, тыңлаулар, тавыш бирү һәм аларга карарлар кабул итү өлешендә әлеге Регламентның нигезләмәләре бу бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.

3. Район Советы, район Советы комитетлары һәм комиссияләре эшчәнлегенең аерым тәртибе гамәлдә булган чорда элемтә мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләреннән файдаланып видеоконференцэлемтә рәвешендә үткәрелергә мөмкин (алга таба – дистанцион формада район Советы, комитет, район Советы комиссиясе утырышы).

48 Статья.

1. Район Советы утырышын дистанцион формада уздыру турында карар район Советы Рәисе, район Советы комитетлары һәм комиссияләре утырышы - комитет, комиссия рәисе тарафыннан, район Советы Рәисенә мәҗбүри хәбәр итеп, кабул ителә.

2. Район Советы, комитет, район Советы комиссиясе утырышында район Советының күрсәтелгән органнары әгъзалары булмаган затларның дистанцион рәвештә катнашуы район Советы Рәисе, комитет рәисе, район Советы комиссиясе карары буенча, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив-хокукый актларның таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3. Район Советы, комитет, район Советы комиссиясе утырышын дистанцион рәвештә уздырганда карала торган мәсьәлә буенча карар сораштыру рәвешендә тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

49 Статья.

1. Эшчәнлекнең аерым тәртибе гамәлдә булган чорда, кичектергесез очракларда, район Советы, комитет, район Советы комиссиясенең аларның карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча карарлары депутатлар, комитет депутатларының, комиссияне сораштыру рәвешендә тавыш бирү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

2. Депутатларны сораштыру юлы белән тавыш бирү район Советы Рәисе карары буенча әлеге Регламентның 21.1. статьясында каралган тәртиптә уздырыла. Комитет, комиссия депутатларын сораштыру рәвешендә тавыш бирү тиешле комитет, комиссия рәисе карары буенча үткәрелә һәм комитет, комиссия

әгъзасының һәр мәсьәлә буенча белдергән фикере күрсәтелә торган сораштыру кәгазьләрен кулланып гамәлгә ашырыла. Депутатларның, комитет депутатларының, комиссиянең сораштыру кәгазе район Советына, шул исәптән элемтәнең электрон элемтә чараларын кулланып, җибәрелергә мөмкин.

50 Статья.

1. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турында карар район Советы Президиумы тарафыннан кабул ителә. Дистанцион рәвештә утырыш уздыру турындагы карарда әлеге утырышка чакырылган затлар исемлеге билгеләнергә мөмкин. Район Советы утырышында катнашу мөмкинлеге Мөслим муниципаль районы Башлыгына, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Мөслим районы прокурорына мәҗбүри тәртиптә тәэмин ителә.

2. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турындагы мәгълүмат тиз арада район Советы депутатларына җибәрелә һәм «Интернет» челтәрендә район Советының рәсми сайтына урнаштырыла.

3. Район Советының дистанцион утырышында карарлар, электрон системаны кулланмыйча, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорау бирүгә язылу, чыгышлар ясауга язылу утырышта катнашучы депутатларны сораштыру юлы белән (кул күтәреп, дистанцион утырышның башында район Советы депутатлары билгеләгән башка ысуллар белән) башкарыла.

4. Район Советы утырышы дистанцион формада видеоконференцэлемтә режимында үткәрелә.

5. Район Советы карары буенча чакырылган затлар район Советының дистанцион утырышында мәгълүмати-телекоммуникация элемтә челтәрләреннән файдаланып катнаша ала.

51 Статья.

1. Район Советы, комитет, комиссия утырышын уздырганда, дистанцион формада утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

2. Район Советы, комитеты, район Советы комиссиясе, парламент тыңлауларының беркетмәсенә дистанцион рәвештә утырышны үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары турында белешмәләр, утырышның башлану һәм тәмамлану вакыты, шулай ук әлеге регламентта каралган башка белешмәләр кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио - һәм видеоязмасы теркәлә.».

1.3. Регламентның XII бүлеген түбәндәге эчтәлекле XIII бүлек дип санарга:

«XIII бүлек. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

52 Статья. Район Советы эше турында мәгълүмат

1. Район Советы, даими комиссияләр, башка органнар, район Советы депутатлары эшчәнлеге массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

2. Район Советы елына кимендә бер тапкыр массакүләм мәгълүмат чараларында үзенең эшчәнлеге турында хисап бастырып чыгара.

53 Статья. Регламентның үтәлешен контрольда тоту

1. Әлеге регламентның үтәлешен контрольда тоту район Башлыгы - район Советы Рәисе, аның урынбасары тарафыннан башкарыла.

54 Статья. Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Әлеге Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар, район Башлыгы - район Советы Рәисе, депутатлар, депутат төркемнәре, даими комиссияләр инициативасы буенча, Район Советы тарафыннан депутатларның билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

2. Мөслим муниципаль районы Советына, санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчы, үз эшчәнлегендә әлеге карарның 1.2 пунктына таянып эш итәргә кирәк.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында (https://muslumovo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы
Советы Рәисе Р.Х. Муллин